

Матур гына 8 март бәйрәмен vткәрдек. Хатын-кызларыбыз чәчәкләр бәйләменнән, бvләкләрдән кояш кебек балкыдылыр. Тиз арада табигать тә жанланып китте: бер-ике кон эчендә жылытты, янгыр яуды, елгаларыбыз су белән тулды, боз аккан урыннар да бар.
Табигатебез жанланды һәм шунын белән бергә тиз генә юлларны, кvперләрне, ойләрне су басты. Шулай, 11 мартта оператив кинәшмәдә Мордовия Главасы Артём Здунов язгы традицион актуаль проблемага - ташу вакытында автомобиль кvперләрен су басуга игътибар итте. Тобәктә су басу белән автомобиль элемтәсе тулысынча бозылган берничә территория бар, кайбер торак пунктларда яшәvчеләр доньядан аерылган булалар. Республика житәкчесе ассызыклаганча, мондый территорияләр билгеле. Ташуга алдан әзерләнергә кирәк, ди Артём Алексеевич.      «Барлык вакытларда да бер vк нәрсә: тvбән кvперне су кисеп алган торак пункт. Әйдәгез, су басуга әзерләник! Ин куркыныч урыннардан башлыйк - жыелма конструкцияләр урнаштырыйк. Әгәр алар кешеләргә киләчәктә кирәк булса, аларны калдырыйк. Республикада су басу сезоны ышанычлы vтсен очен, шунын белән шогыльләнегез», - диде Артём Здунов.
Әмма кар тиз эрv, янгыр яву әзерләнергә кvп вакыт бирмәде. Мәсәлән, Мордовия Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгынын Дәvләт автоинспекциясе хәбәр иткәнчә, 12 мартта Ковылкино районы территориясенен 53 км автомобиль юлында, Рузаевка – Ковылкино - Торбеево (Рус Коломасово авылы, Паево авылына борылыш арасында) юл полотносы су астында кала. Хәзерге вакытта юл - патруль хезмәте һәм юл хезмәте хезмәткәрләре урында эшли. Хәл начарланган очракта юлнын әлеге участогында хәрәкәтне чикләv мәсьәләсе хәл ителәчәк.
Шул ук конне Кадошкино районы Большие Поляны авылы халкы су стихиясе белән корәшеп алды. Авылны урап аккан Исса елгасына су юлларын, асфальт юлын капламасын дип, Капкаев Рашид Рустам улы vз транспорты белән Насакан Потьма тирәсендәге су юллары ачып йорде, авыл житәкчесе Наилә Хафиз кызы Долотказина елга аша vткән тvбән кvпернен перилаларын салдыртып юлны япкан. Ул 12 сәгатьтә су 82 см кvпер остенә кvтәрелсә, 17 сәгатьтә 1 метр 86 см кvтәрелде, диде. Тонлә Ленина урамындагы 58, 56, 54 йортларны су басудан Долотказин Ильдар Али улы, Долотказин Руслан Альберт улы, Капкаев Рашид Рустам улы, авыл житәкчесе житәкчелегендә, коткардылар. Ә су батырунын топ сәбәбе – vткән ел юлга асфальт жәйгәндә юлларны тозv технологиясен тулысынча башкармауда, язгы ташу очен жайланмаларны дорес урнаштырмауда, су агу юлларын каплауда.
Уникесендә Саранск шәһәрен дә ташу сулары батырып алды: Рабочая урамы янындыгы Инсар елгасы аша һәм Юбилейный 1 һәм 2 микрорайоннары арасындагы Тавла елгасы аша тvбән кvперләр вакытлыча ябылды. Ромоданово районы Кочуново авылындагы 14 хужалыкны су баскан, дип яза интернет челтәр. МЧС хезмәткәрләре авыл халкына ярдәм итә.
14 мартта бу теманы яктырткан пресс-конференция vтте. Мордовиядә биш районда жиде тvбән сулы кvпер су астында калган. Су басу зонасында бvгенге кондә 5 торак йорт һәм 323 йорт яны участогы бар. Мондый мәгълvматларны Мордовия матбугат vзәгендә узган конференциясендә Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгынын

Мордовия Республикасы буенча Баш идарəсе начальнигы Сергей Викторович Репин белдерде.
«Быел кар бик тиз эри башлады, ə елгалар бер ай алдан ачылды. Янгыр һəм жылы һава торышы аркасында кvп су жыелган, һəм бу су басуга сəбəп булган. Су шундый дəрəжəгə кvтəрелде, алга таба кvтəрелv шактый житди нəтижəлəргə китерергə момкин. Бездə барлык кирəкле кочлəр һəм чаралар бар, əмма эштə кайбер проблемалар белəн дə очраштык. Алар, беренче чиратта, йорт яны участокларын тоту, vткəрv торбаларын контрольдə тоту, су бvлеп бирелергə тиешле каналларны чистарту белəн бəйле», - дип анлатты С.В.Репин.
Шулай ук ташуга əзерлек, кон кадагы булган сунын кайсы пунктларда нинди дəрəжəдə vсvе, язгы процессларны фаразлау, яз башы табиги кvренешлəргə каршы тору чаралары, коч һəм чараларнын су басуга əзерлеге, язгы су басуга халыкнын иминлеген тəэмин итv, су басу нəтижəлəрен киметv буенча башкарыла торган чаралар комплексы турында Светлана Евгеньевна Хлевина (Мордовия метеорология һəм əйлəнə тирə мохит мониторингы vзəге начальнигы), Андрей Геннадьевич Наумов (РМ гражданнар оборонасы эшлəре һəм гадəттəн тыш хəллəр буенча Дəvлəт комитеты рəисе), Юрий Александрович Белоусов (Баш идарə начальнигы урынбасары - гражданнар оборонасы һəм халыкны саклау идарəсе начальнигы), Алексей Александрович Любимов (Югары Волга БВУ житəкчесе урынбасары - Мордовия буенча ОВР начальнигы), Александр Джигантович Трегулов (Мордовия буенча Россия МЧС Баш идарəсенен ГИМС vзəге начальнигы) сойлəделəр.
Белгечлəр Мордовиядə быелгы язгы су басу сонгы елларда ин шаукымлысы булыр дип фаразлый. Ə иртə агып чыгу һава температурасынын кvтəрелvе һəм янгырлар белəн анлатыла. Тунган жир суны vзлəштерми, шуна кvрə ул остə бара. «Эретvне акрынайтуга ометлəнергə кирəкми, ə су шунда ук китмəячəк. Жомгага янгырлар кабат котелə, бу су кvтəрелv ихтималын арттыра. Пикны боз эри башлагач һəм елгалар ярларыннан чыккач котəчəкбез»,- дип саный Мордовия ЦГМС житəкчесе Светлана Евгеньевна Хлевина. Ул Исса елгасында су дəрəжəсенен куркыныч билгесенə кадəр нибары 30 сантиметр, Инсарда 76 калганын билгелəп vтте.
Мордовиядə 150лəп вакытлыча урнаштыру пункты су баскан территориялəрдə яшəvчелəрне кабул итəргə əзер. «2012 ел тəжрибəсе буенча шуны əйтə алам: бу пунктларга кvченергə телəvчелəр аз иде, - ди РМ Гражданнар оборонасы һəм гадəттəн тыш хəллəр буенча дəvлəт комитеты рəисе Андрей Наумов. - Кvпчелек кеше туганнары һəм танышлары белəн кала. Шулай да, мондый пунктлар бар, алар нигездə мəгариф, спорт, социаль объектлар биналарында урнашкан. Саранскида бу кунакханəлəр һəм хостеллар».
Андрей Наумов сvзлəренчə, быел су басу белəн бəйле хəл торле сценарийлар буенча vсəргə момкин, һəр нəрсəгə əзер булырга кирəк.
Чыгышларда яз башу ташуына əзер булырга чакырдылар. Су батырган урыннарда эш алып барыла, ярдəм кvрсəтелə һəм су батырмасын очен барлык чаралар да башкарыла.

**Наилə НАСЫРОВА**